Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР

№ 9 27.04.2021

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау хакында»гы 01.02.2021 елның 2-2 карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр керту турында

"Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр керту турында" 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авылы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авылы Башкарма комитетының «Капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын раслау турында» гы 01.02.2021 елның 2-2 номерлы карары белән расланган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр керту:

1.1. 6 пунктның 6.1.пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук күпфатирлы йортлар, торак йортлар (территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә мондый йортлар төзү очракларыннан тыш) төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).

2. Әлеге карарны Полянка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Полянка авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе: Г.Г. Сибгатуллина